**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Клубная, д.1а, село Кутема, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Клуб урамы, 1а йорты, Күтәмә авылы, 423112

тел.+7(84396) 4-30-88, e-mail: Kut.Cmn2@tatar.ru

**№ 104** **18 декабрь 2023 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

«Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең 2014 елның 17 декабрендәге № 116 карарына үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ, 2023 елның 10 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» № 286-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең 2014 елның 17 декабрендәге №116 карарына (Советның 2023 елның 13 мартындагы №79 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «үз карамагындагы муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр

конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;».

1.2. 2.5 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәтенең кадрлар бүлеге үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Н.Г. Сабиров